ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.7, с. Шеланга,
422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Совет ур.,16 нче йорт, Килде авылы,
422586

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

07.11.2019

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48

37

с. Кильдеево

Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегендә
гражданнарның үзара салым акчаларын җыю
Тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Уставы нигезендә, 2019 елның 6 ноябрендәге 3 нче номерлы гражданнар җыенында кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру максатларында, Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты карар чыгарды:

1. Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Килди авыл җирлеге башлыгы Бурдин В.М.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Килди авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2019 елның
07 ноябрендәге 37 номерлы карарына
1 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегендә
гражданнарның үзара салым акчаларын җыю
Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлегендәге үзара салым акчасын җыю кагыйдәләрен билгели.
2. Гражданнарның үзара салым акчасын түләү гражданнар җыенында катнашуларына бәйсез рәвештә, Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар һәм алар тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйле рәвештә 2020 елның 1 гыйнварыннан 2020 елның 31 мартына кадәр гамәлгә ашырыла.
3. Түбәндәге категория гражданнар үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:
а) Бөек Ватан сугышында катнашучылар.
Аерым категория гражданнар өчен:
а) 1 төркем инвалидлар,
б) Бөек Ватан сугышы ветераннары
түләү күләме гражданнар җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә.
4. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы имза яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән гражданнарга җиткерелә.
Хәбәрнамәдә (хәбәр итү) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.
5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.
6. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша почта күчерүе аша яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша башкарыла( https://uslugi.tatarstan.ru/).
7. Керем касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслый.
8. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.